Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Советы
карары

2018 елның 29 декабре № 103

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Советының
2017 елның 6 сентябрендәге
«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Осинники авыл җирлеге
Советы депутаты статусы турында «гы
54 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге Советы гамәлдәге законнарга туры китерү максатында карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советының 2017 елның 6 сентябрендәге 54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын “сәяси партия" сүзләреннән соң "билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
- Осинники авылы, Яшьләр урамы, 9А йорт (административ бина);
- Осинники авылы, Лесная ур., 2 йорт (Осинники авыл мәдәният йорты)
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге Советы Рәисе Сагдеев А.Х.